5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. Яңартылган стандарт таләбе буларак уку грамоталылыгы // Современное обра-зование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 1 (20). URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/04/2024_1_gilyazova.pdf

УДК 372.8

**Гыйләҗева Лилия Гыйльметдин кызы[1], Һадиева Гөлнара Васил кызы[2]**
[1,2] Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе, Россия, Казан шәһәре

## Яңартылган стандарт таләбе буларак уку грамоталылыгы

***Аннотация.*** Мәкаләдә туган (татар) тел һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларда уку грамоталылыгы формалаштыру һәм, шулай ук, диагностика эшенең структурасы һәм биремнәргә мисаллар карала.
***Терәк сүзләр:*** яңартылган ФДББС, уку грамоталылыгы, текст, аңлап уку

**Liliya G. Gilyazova[1], Gul'nara V. Khadieva[2]**
[1,2] Institute of Education Development of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

## Reading Literacy as a Condition of an Updated Standard

***Abstract.*** The article discusses the formation of reading literacy of students in the lessons of their native (Tatar) language and literature, as well as the structure of diagnostic work and examples of tasks.
***Keywords:*** updated Federal State Educational Standard, reading literacy, text, semantic reading

Бүгенге заман мәгариф системасында өстенлекле бурычларның берсе булып, функциональ грамоталылык формалаштыру тора, ул үз чиратында уку, математик, фәнни-табигый һәм финанс грамоталылык, шулай ук, креатив фикерләү һәм глобаль компетенцияләрдән тора[1]. Туган (татар) тел һәм әдәбият дәресләрендә уку грамоталылыгы формалаштыру да замана таләбе буларак аңлашыла.

Уку грамоталылыгы — текстларны интерпретацияләү осталыгы, яшерен мәгънә һәм аларның аңлатмасын эзләү, анализлау. Ул текстларны аңлау һәм анализлау күнекмәсен, үз фикерләреңне әйтә һәм формалаштыра белү, алган белемнәрне шәхси һәм социаль тормышта куллана белүне үз эченә ала [1, б. 4].

Уку грамоталылыгын бәяләү — укучының функциональ грамоталылыгын бәяләүнең бер нигезе булып тора. «Текстларны кабул итү, аңлау һәм куллану буенча оештырылган катлаулы эшчәнлек буларак уку үлчәү предметы булып тора» [2, б. 11].

Укый белү һәм укыганны аңлау төп мәктәптә уңышлы белем алуның мөһим шарты булып тора. Кызганычка каршы, күпчелек укучылар бу мөһим күнекмәгә ия түгел. Нәтиҗәдә укучыларда тиешле материал үзләштерелми, ә бу исә предмет нәтиҗәсе дә тулысынча формалаштырылмый дигән сүз. Билгеле булганча, предмет нәтиҗәләренә ирешү төрле стильдәге текстлар белән эшләү нигезендә тормышка ашырыла.

[1] Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования: официальный сайт. URL:https://fgos.ru/

© Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В., 2024

Дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлектә 5 нче сыйныф укучыларына уку белән бәйле түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә була [3, б. 3]:

– мәгълүматны табу һәм анализлау;

– фактик материалны тәнкыйди бәяләү;

– гадәти тел белән формалаштырылган бирем шартларын предмет өлкәсе теленә күчерә белү;

– биремне үтәүнең стандарт булмаган ысулларын таба белү;

– мөстәкыйль нәтиҗәләр ясый белү күнекмәсе һәм аларны бәйләнешле һәм логик яктан дөрес итеп структуралаштырылган телдән яки язма текст формасында чагылдыра белү;

– төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларны чагыштыра белү күнекмәсе;

– график мәгълүмат белән эшли белү.

Дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә уку грамоталылыгын формалаштыруга тәкъдим ителә торган текстлар укучылар көндәлек тормышта очраша торган проблемалар белән аваздаш булырга тиеш. Биремнәрнең контекстын көндәлек тормышта барлыкка килә торган проблемалы ситуацияләргә якынайту укучыларның мотивациясен арттырырга ярдәм итә. Текстларга иллюстратив материал һәм төрле проблемаларны чишү өчен кирәк булган уку грамоталылыгының барлык төрләрен формалаштыруга юнәлтелгән сораулар тәкъдим ителә. Түбәндә тәкъдим ителгән бирем иллюстратив материал белән бәйле.




*Казан/Татарстан турында мәгълүмат булган слайдны карагыз. Слайдта җавабы булмаган 3 сорау төзегез.*

Диагностик эш метапредмет нәтиҗәләренең (танып белү) нигезен тәшкил иткән мәгълүмат белән эшләү һәм уку кебек универсаль уку гамәлләрен тикшерүгә юнәлтелгән булырга тиеш. Уку грамоталылыгын бәяләү буенча диагностика эшендә билгеле бер теманы чагылдырган һәм төрле стиль, жанрга караган 2 яки 3 текст сайлап алына һәм бу текстлар нигезендә биремнәр эшләнелә. Алга таба уку белән бәйле булган кайбер биремнәргә, эш төрләренә тукталып китик.

Тексттан мәгълүматны табу һәм анализлау — уку грамоталылыгын формалаштыруда төп эш төре. Биремнәрне төрлечә тәкъдим итәргә була:

— Тексттагы мәгълүматка туры килә торган раслауны сайлагыз.

— Барлык биремнәрдә очрый торган мәгълүматка туры килә торган ике раслауны сайлап алыгыз.

— Тексттагы ... диган гыйбарәгә автор нинди мәгънә сала?

— Текст фрагменты һәм аның мәгънәсе арасында бәйләнешне билгеләгез.

Фактик материалны тәнкыйди бәяләүгә нигезләнгән биремне түбәндәгечә формалаштырып була:

— Сез кайсы фикер белән килешәсез? Укылган текст нигезендә үзегезнең җавапны аңлатыгыз.

График мәгълүмат белән эшли белү күнекмәсен формалаштыру максатыннан тәкъдим ителә торган биремнәр:

Бирелгән шкалада ... вакыт аралыгын билгеләгез.

Укылган мәгълүматны кулланып, таблицаның буш урыннарын тутырыгыз.

Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләбе буларак туган (татар) тел һәм әдәбият дәресләрендә, шулай ук, дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында укучыларда уку грамоталылыгы формалаштыру аша төрле стильләргә караган текстларны укыганда югары нәтиҗәләргә ирешү мөһим.

Файдаланылган әдәбият

1. Забродина Н.П. Читательская грамотность: пособие по развитию функциональной грамотности старшеклассников. Москва: Академия Минпросвещения России, 2021. 80 с.

2. Основные подходы к оценке читательской грамотности учащихся основной школы // Мониторинг формирования и оценки функциональной грамотности. 74 с. https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2941962.pdf.
3. Дергилёва Ж.И. Смысловое чтение. 5 класс. Анализ текстов разных стилей. Москва: Издательство «Интеллект-Центр», 2023. 88 с.

References

1. Zabrodina N.P. Reading literacy: a manual for the development of functional literacy of high school students. Moscow, Akademiya Minprosveshcheniya Rossii, 2021, 80 p.
2. Basic approaches to assessing the readership of basic school students. Monitoring the formation and evaluation of functional literacy. 74 p. URL: https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2941962.pdf
3. Dergileva Zh.I. Meaningful reading. 5th grade. Analysis of texts of different styles. Moscow, Intellekt-Tsentr Publ., 2023, 88 p.